**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫ£
ЭТИЛ СПИРТЫ hЪМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ЌИТЕШТЕРYНЕ,
ЪЙЛЪНЕШТЪ ЙЇРТYНЕ,
СЫЙФАТЫН ДЪYЛЪТ ТИКШЕРYЕН
ТЪЭМИН ИТY hЪМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДЪYЛЪТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**

(Татарстан Республикасы Д¥YЛ¥Т алкоголь
инспекциясе)

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: cla@tatalc.ru, http://www.tatalc.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

---

19.12.2016 № 12-07/127

На № ____________ от _________________

Административ штрафларны түләү
буенча бурычны түләтүгә
ышанычның юклыгын тану турында
карарны кабул итү тәртибен раслау
хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясындагы 4 пункты, “Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында” 06.05.2016 ел, № 393 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 2 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан салына торган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карарлар кабул итү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А. Марченко**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең
19.12.2016ел, № 12-07/127 боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан салына торган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карарлар кабул итү тәртибе

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 31.7, 31.9 статьялары нигезендә, түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан салына торган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә ышаныч юк дип танылa:

1) физик зат – административ штраф түләүче үлгәндә яки Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгәндә;

2) хосусый эшмәкәр – административ штраф түләүче “Бөлгенлеккә төшү турында (банкротлык) турында” 26 октябрь, 2002 ел, № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә банкрот дип танылганда;

3) оешманың – административ штраф түләүченең оешма милкенең җитәрлек булмавы һәм (яки) әлеге оешманың гамәлгә куючылары (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләнелмәгән бурычы өчен бетерелүе;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан салына торган административ штрафлар буенча, җирле бюджетлар кеременең баш администраторы буларак, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең, бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызу турында суд тарафыннан билгеләмә чыгарылуга бәйле рәвештә, бюджетка бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд тарафыннан акт кабул ителгәндә;

5) суд приставы-башкаручы тарафыннан “Башкару производствосы турында” 2 октябрь, 2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның (алга таба – № 229-ФЗ Федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешендә 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, түбәндәге очракларда, бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узганда:

бурыч күләме банкротлык турында эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законында билгеләнгәнчә, бурыч күләме бурычлыга карата таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

бюджетка түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган

процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә средстволарның булмавы сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда;

6) РФ КоАП 31.9 статьясында билгеләнгән административ җәза билгеләү турында карарны үтәүнең дәгъва бирү срогы (карар законлы көченә кергәннән соң ике ел тәшкил иткән) чыкканда, мондый срокка тәнәфес ясау, туктатып тору яки озайту турында нигезләр булмаганда (билгеләнгән срокта түләнмәгән административ штрафларга карата);

7) амнистия акты чыгарылганда, мондый акт административ җәза куллануны юкка чыгарганда;

8) кылынган гамәл өчен административ җаваплылык билгеләүче закон яки аның нигеләмәсе үз көчен югалткан дип танылганда, бер үк вакытта кылынган гамәл өчен административ җаваплылыкны юкка чыгаручы һәм кылынган шул ук гамәл өчен җинаять җаваплылыгын билгеләүче закон нигезләмәләренең үз көченә керүе очрагыннан тыш;

9) административ штраф билгеләү турында карар юкка чыгарылганда.

2. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карар кабул итү өчен нигезләрнең барлыгын раслаучы документлар булып тора:

а) бюджет керемнәренең баш администраторы буларак, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең бюджет хисабыннан Татарстан Республикасы җирле бюджетларына административ штрафлар түләү буенча исәпкә алына торган бурыч суммалары турында өземтә;

б) Татарстан Республикасы җирле бюджетларына административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмә;

в) бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

гражданлык хәле актларын теркәүгә алуны хәл итүче органнан алынган, физик зат – административ штраф түләүченең үлүе яки Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе турында дәлилләүче документ (бу Тәртипнең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда);

административ штраф түләүче хосусый эшмәкәрнең банкрот дип танылуына бәйле рәвештә эшчәнлегенең туктатылуы турында Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (бу Тәртипнең 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда);

оешма – администартив штраф түләүченең бетерелүенә бәйле рәвештә эшчәнлеген туктатуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (бу Тәртипнең 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда);

бюджет керемнәренең баш администраторы буларак, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең, бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызу

турында суд тарафыннан билгеләмә чыгарылуга бәйле рәвештә, бюджетка бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд акты;

№ 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча түләтүчегә башкару документы кире кайтарылганда, башкару производствосының тәмамлануы турында суд приставы-башкаручының карары (бу Тәртипнең 1 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда).

3. Административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычны югалту дип тану буенча эшне оештыру максатыннан чыгып, активларның керү һәм чыгу комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә, аның персональ составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

4. Комиссия эшен оештыруны тәэмин итү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлеге тарафыннан хәл ителә.

5. Комиссиядә җирле бюджетларга административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында мәсьәләне карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кызыксынулы структур подразделениесе административ һәм суд практикасы бүлегенә бурыч китереп чыгарган һәм бу бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану тәкъдим ителә торган түләүләр турында мәгълүматлардан торучы хезмәт язуын (аңа бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар кушып бирелә) җибәрә.

6. Административ һәм суд практикасы бүлеге, документларның тулылыгын һәм алардагы мәгълүматларның тулылыгын тикшергәннән соң, Комиссиягә карауга җибәрә.

7. Комиссиягә рәис җитәкчелек итә, рәис Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә.

8. Комиссия, бу Тәртипнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм документлар булганда, кварталга кимендә 1 тапкыр утырышлар үткәрә.

9. Комиссия утырышында, Комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 өлеше катнашканда, Комиссия карарлары, гамәлдә була ала, дип танылa.

10. Тапшырылган документларны Комиссия тарафыннан карап тикшерү һәм карар проектын әзерләү срогы утыз эш көненнән артмаска тиеш.

11. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары кул куя.

13. Комиссия, бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәлре буенча, Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы нигезендә карар кабул итә.

Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында Комиссия карары Комиссиянең барлык әгъзалары имзалаган акт нигезендә рәсмиләштерелә, һәм бу акт түбәндәге мәгълүматлардан тора:

а) оешманың тулы атамасы (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме) (соңгысы – булганда);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешманың салым түләүчесен учетка кую сәбәпләре коды (физик затның салым түләүчесенең идентификация номеры);

в) бурыч китереп чыгарган штраф турында мәгълүматлар;

г) бюджетка түләүләр буенча бурычны исәпкә алуда кулланыла торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификациясе коды, аның атамасы;

д) бюджетка түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) бюджетка административ штраф түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карар кабул итү датасы;

ж) Комиссия әгъзаларының имзалары.

14. Җирле бюджетка административ штраф түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән акт Татарстан Республикасы Дәүдәт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

15. Комиссия тарафыннан түләтүгә ышанычның юклыгы танылган, бюджетка административ штрафны түләү буенча бурычны бюджет учетыннан сызып ташлау, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең финанс контрольлеге бүлеге тарафыннан хәл ителә.